| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «МУКМИН-КАРАТАЙСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «МӨЭМИН-КАРАТАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

Мөэмин-Каратай

2020 елның 12 февраленнән №4

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына коррупциягә каршы көрәш турында законнарын камилләштерү максатларында үзгәрешләр кертү хакында» 16.12.2019 № 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Лениногорск шәһәре прокуратурасының 2020 елның 14 гыйнварындагы 02-08-03 номерлы протестын, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы протестын карап тикшергәннән соң, КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 1 августындагы 17 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану турында «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрне яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы идарәсенең коллегиаль органнары составына керүенә алу тәртибе турында нигезләмә» расланды.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мөэмин-Каратай авылы, Механизаторлар ур., 31 й. адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендта игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (leninogorsk.tatar.ru) “Авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
"Мөэмин-Каратай авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе

А.А. Ханнанова